**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мемдель, ул. Кооперативая, 30

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив урамы, 30

тел./факс 8(84365) 60-2-37,e-mail:Memdel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 июнь 2019 ел** **№ 136**

**Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 октябрендәге 114 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге советына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 01 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

**РЕШИЛ:**

1. «Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 октябрендәге 114 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;».

2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы анда катнашканда, гражданнарның җыены, хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысы берьюлы бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән Мәмдәл авыл җирлеге уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Башкаруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет Рәисе Урынбасары
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Сафиуллин